# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**03 декабрь 2021 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Чалпы торак пунктында Яшьләр, Яңа, Гагарин, Казанская, Ленин, Садовая урамнары буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (вак таш җәелгән юлларны карап тоту, юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Чалпы торак пунктында җирлекне яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү);
- Чалпы торак пунктында тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәт күрсәтүгә түләү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү);
- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эш өчен түләү, триммер өчен ГСМ и запас частьләр сатып алу, территорияләрне санитар чистарту буенча хезмәтләр, территорияләрне яшелләндерү буенча чаралар, Чалпы торак пунктында МАФлар сатып алу һәм урнаштыру);
- Чалпы торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне»нә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү, сәхнә костюмнары, музыка аппаратурасы сатып алу);

- Чалпы авылында, һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен ремонтлау ( облицовкалы кирпеч сүтү һәм профнастил белән тышлау, буяу, агарту, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны,  кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Чалпы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм  Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru)  урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы _______________ А.М.Мөхәмәтшин